**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2955**
**10.06.2019**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2018 елның 9 апрелендәге 1931 нче карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсе 1 пунктының 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакындагы нигезнамәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турындагы нигезнамә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Мәдәният һәм ял паркы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2018 елның 9 апрелендәге 1931 нче карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1, 9, 10, 11, 19 юлларны төшереп калдырырга.

2) түбәндәге эчтәлектәге 53, 54, 55, 56, 57, 58, 59 юллар белән тулыландырырга:

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге (бер сеанс) | Чик тариф сумнарда |
|---|---|---|---|
| 53 | «Аквазорб» су шарлары | 3 мин | 120 |
| 54 | Биоробот | 3 мин | 120 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 55 | «ФутуРифт» виртуаль чынбарлык | 5 мин | 120 |
| 56 | Чаңгылар | 1 сәгать | 100 |
| 57 | Тимераяклар | 1 сәгать | 100 |
| 58 | Тюбинглар | 1 сәгать | 150 |
| 59 | Бәдрәф | 3 мин | 10 |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин